СОВЕТ
НАБЕРЕЖНО-МОРКВАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ЯР БУЕ МОРКВАШЫ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ — КАРАР

30.09.2016 — с. Набережные Моркваши — № 20-85

Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча җирле референдум үткәрү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 12.06.2002 елдан № 67-ФЗ Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, №131-ФЗ Федераль законның 22, 56 ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 20 статьясындагы 1 пунктында, Яр буе Морквашы авыл җирлеге Уставының 11 пункты, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 2016 елның 20 сентябрендәге 19-82 номерлы Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы карары, «Җирле референдум уздыру инициативасы турында» 2016 елның 20 сентябрендәге 12 номерлы Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы карары нигезендә,

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге Советы
карар итте:

1. 2016 елның 20 ноябренә Яр буе Морквашы авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.
2. Җирле референдумга чыгарыла торган сорауны распарга:

"2016 елда җирле референдумда катнашу хокукына ия булган авыл җирлегенең һәр кешесеннән 400 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару буенча алынган акчалар юллау белән килешәсезме:

- Яр буе Морквашы авылының Зеленая урамы, Красавин урамы, Пустые Моркваши поселогында Үзәк урамы буенча балалар мәйданчыклары төзү.
Яр буе Морквашы авыл җирлегендә контейнер мәйданчыклары төзү, контейнерлар сатып алу .
Лесные Моркваши авылы: 2 шт күләмендә контейнер мәйданчыклары төзү, 6 шт күләмендә контейнерлар сатып алу;
Никольский бистәсе: 3 шт күләмендә контейнер мәйданчыклары төзү, 9 шт күләмендә контейнерлар сатып алу;

Пятидворка п.: 1 данә контейнер мәйданчыклары төзү, 3 шт күләмендә контейнерлар сатып алу,
Десятидворка п.: 1шт. күләмендә контейнер мәйданчыклары төзү, 3 шт. күләмендә контейнерлар сатып алу,
Покровка авылы: 2 данә контейнер мәйданчыклары төзү, 6 шт контейнерлар сатып алу,
Яр буе Морквашы авылы: 3 шт күләмендә контейнер мәйданчыклары төзү, 15 данә контейнер сатып алу,
Пустые Моркваши ав.: 1шт күләмендә контейнер мәйданчыклары төзү, 3 данә контейнер сатып алу.;

ӘЙЕ ЮК

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карар аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

Югары Ослан муниципаль районы
Яр буе Морквашы авыл җирлеге башлыгы И.Х.Гаязов